КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 18 ноябрь г.Казань № 885

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче; 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче; 2013 ел, 11 май, 313 нче; 2013 ел, 29 июнь, 455 нче; 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче; 2014 ел, 28 май, 362 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 25 август, 613 нче; 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче; 2015 ел, 4 август, 565 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1025 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 611 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 983 нче; 2017 ел, 18 май, 292 нче; 2017 ел, 27 сентябрь, 731 нче; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2017 ел, 31 октябрь, 827 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

бу карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагындагы медицина оешмалары һәм Татарстан

Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

бу карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләрнең эшче гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары буенча һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

3 нче бүлектә:

3.3 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәтнең интенсивлыгы өчен түләүләр.»

3.4 нче пунктта:

беренче, дүртенче – сигезенче абзацларда «эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен» сүзләрен «хезмәтнең интенсивлыгы өчен түләүләр» сүзләренә алыштырырга;

4 нче бүлектә:

4.1 нче пунктның икенче абзацында «авыр эшләрдә, зарарлы һәм (яки) куркыныч йә башка махсус хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә» сүзләрен «зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә» сүзләренә алыштырырга;

4.2 нче пунктта «авыр эшләрдә, зарарлы һәм (яки) куркыныч йә башка махсус хезмәт шартлары булган эшләрдә» сүзләрен «зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә» сүзләренә алыштырырга;

4.6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 147 статьясы һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләрнең эшче гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары буенча һөнәри квалификация төркемнәренә керүче һәм бу Нигезләмәгә теркәлгән 3 нче кушымтада китерелгән зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә өстәмә түләүләрнең тәкъдим ителә торган күләмнәре нигезендә билгеләнә.

Хезмәт өчен түләүнең яңа системасын кертү вакытына әлеге түләү аны моңа кадәр алып барган барлык хезмәткәрләргә билгеләнә. Шуның белән бергә эш бирүче хезмәт шартларын махсус бәяләү буенча чаралар күрә. Әгәр дә хезмәт шартларын махсус бәяләү йомгаклары буенча эш урыны куркынычсыз дип танылса, әлеге түләү гамәлгә ашырылмый. Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләрнең минималь күләме вазыйфаи хезмәт хакыннан 4 процент күләмендә хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә билгеләнә.

Хезмәткәрләргә әлеге түләүләрне билгеләү турындагы карар, аларны финанс чаралары белән тәэмин итүне исәпкә алып, учреждение тарафыннан кабул ителә.»;

Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтаны бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

Нигезләмәгә 3 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең бу карар нигезендә билгеләнә торган эш хакы, хезмәткәрләрнең вазыйфаи йөкләмәләре күләмен саклау һәм алар шул ук квалификациядәге эшләрне башкару шарты белән, бу карар нигезендә хезмәт өчен түләүнең яңа шартларына күчү вакытына гамәлдә булган хезмәт өчен түләү системасы буенча түләнелә торган эш хакыннан кимрәк була алмый.

3. Татарстан Республикасының дәүләт оешмалары җитәкчеләренә, хезмәткәрләрнең тиешле һөнәр берлеге органы белән килештереп:

Татарстан Республикасы дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган күмәк шартнамәләренә, килешүләргә, локаль норматив хокук актларына тиешле үзгәрешләрне кертергә;

Татарстан Республикасы дәүләт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәтнең төп шартларына үзгәреш кертү турындагы мәгълүматны бу карар белән билгеләнгән хезмәт өчен түләү системасын керткәнгә кадәр 2 айдан да соңга калмыйча хәбәр итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин